**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**"14" ноябрь 2018 ел** **№ 92**

**Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советының 2017 елның 29 декабрендәге е "Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында” гы Нигезләмә хакындагы 65 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү сәбәпле, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советы гамәлдәге законнарга туры китерү максатында КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советының 2017 елның 29 декабрендәге 65 номерлы карары белән расланган “Иске Казиле авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмә”гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1) шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу (Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр Советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә, съездда (конференция) яки башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәтләре гомуми җыелышында катнашудан тыш), Россия Федерациясе Президенты яки Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашудан тыш; муниципаль берәмлек исеменнән оешма оештыручы һәм муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гамәлгә куючы тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә оешманын идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендэ оештыручы (акционер, катнашучы) булган муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итүдән тыш; федераль законнарда каралган башка очраклардан тыш;».

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерү:
1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;
2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Караталга авылы, Күпер урамы, 5;
3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урамы, 14;
шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

1. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

“Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге”
башлыгы, “Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге”
Советы рәисе И.Х.Сәгдиев